БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » июль 2018 ел № 242

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген төгәлләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2016 елның 20 июнендәге 157 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карары (2016 елның 6 сентябрендәге 205 номерлы, 2016 елның 30 сентябрендәге 214 номерлы, 2017 елның 31 гыйнварындагы 51 номерлы, 2017 елның 6 апрелендәге 126 номерлы, 2017 елның 9 сентябрендәге 239 номерлы, 2017 елның 21 декабрендәге 284 номерлы, 2018 елның 13 февралендәге 76 номерлы үзгәрешләр белән).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р. И. Шакиров